# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлегенең Симетбаш авылында халык җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлегенең Симетбаш авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

**“07” апрель 2024 ел**

**№3**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, “Яңа Кишет авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 25 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлегенең Симетбаш авылында 2024 елның 7 апрелендә «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлегенең Симетбаш авылылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча халык җыены мәсьәләсен яңа редакциядә бәян итү өлешендә халык җыены беркетмәсе төзелде:

“«Сез 2024 елда Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Симетбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыелган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Симетбаш авылында Центральная, Нижняя урамнарда урам-юл челтәрендә вак таш җәеп, автомобиль юлларын тигезләү);
- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам утлары челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән Симетбаш авылында яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру).

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучы сайлау хокукына ия затлар исемлегенә 92 граждан, тавыш бирүдә катнашкан 54 граждан кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 54 кеше тавыш бирде; «Каршы» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Симетбаш торак пунктында гражданнар җыены узды, җыен нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. Гражданнар җыены мәсьәләсен яңа редакциядә бәян итү мәсьәләсе буенча карарны танырга: "Сез 2024 елда Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Симетбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыелган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Симетбаш авылында Центральная, Нижняя урамнарда урам-юл челтәрендә вак таш җәеп, автомобиль юлларын тигезләү);

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам утлары челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән Симетбаш авылында яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру).

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга».

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән Яңа Кишет авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы, Арча районы, Симетбаш авылы, Үзәк урамы, 19а йорты адресы буенча, Арча муниципаль районның (http:// arsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Арча муниципаль районы
Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгы ____________ Ф.И.Ахмадуллин
(имза)(имзаның аңлатмасы)